**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

_07.06.2024_ г. Казань № _78од_________

Татарстан Республикасы Юстиция
министрлыгының Дәүләт граждан
хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә
таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр
конфликтын җайга салу буенча комиссиясе
турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Президентының «Федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтыны җайга салу буенча комиссияләр турында» 2010 елның 1 июлендәге 821 номерлы Указына үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә, боерам:

Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы комиссиясе турында Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2023 елның 7 сентябрендәге 125од номерлы (2023 елның 9 ноябрендәге 161од номерлы боерык белән кертелгән үзгәрешләр белән) боерыгы белән расланган нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.3 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба – дәүләт хезмәткәрләре) Министрлыкта чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турындагы таләпләрне, шулай ук аларның «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль законда, коррупциягә каршы тору максатларында башка федераль законнарда билгеләнгән бурычларны үтәүләрен тәэмин итү (алга таба – хезмәт тәртибенә таләпләр һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләр);»;

3.1 пунктка түбәндәге эчтәлектәге «е» пунктчасын өстәргә:

«е) дәүләт хезмәткәренең хезмәт тәртибенә таләпләрен һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәүгә комачаулаучы аңа бәйле булмаган шартлар барлыкка килүе турында хәбәр итүе.»;

3.4.1 пункты түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Әлеге Нигезләмәнең «б» пунктчасының бишенче абзацында һәм «е» пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамәләр аларны карау нәтиҗәләре буенча мотивацияле бәяләмәләр әзерләүне гамәлгә ашыра торган коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча эш өчен җаваплы зат тарафыннан карала.»;

3.4.2 пунктта «3.1 пунктының «д» пунктчасы» сүзләрен «3.1 пунктының «д» һәм «е» пунктчалары» сүзләренә алмаштырырга;

3.4.3 пунктта:

«а» пунктчасында «3.1 пунктының «д» пунктчасы» сүзләрен «3.1 пунктының «д» һәм «е» пунктчалары» сүзләренә алмаштырырга;

«в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «б» пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында, «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрне һәм белдерүләрне алдан карау нәтиҗәләре буенча мотивацияле бәяләмә, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 3.13, 3.15.1, 3.18, 3.18.1 пунктларына ярашлы рәвештә карарларның берсен яки башка төр карар кабул итү өчен тәкъдимнәр.»;

3.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.7. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән хәбәрнамәләр, кагыйдә буларак, Комиссиянең чираттагы (план) утырышында карала.»;

3.8 пунктта «3.1 пунктның «б» пунктчасы» сүзләрен «3.1 пунктның «б» һәм «е»пунктчалары» сүзләренә алмаштырырга;

3.8.1 пунктның «а» пунктчасында «3.1 пунктның «б» пунктчасы» сүзләрен «3.1 пунктның «б» һәм «е»пунктчалары» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлектәге 3.18.1 пунктны өстәргә:

«3.18.1. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «е» пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәренә бәйле булмаган шартларның барлыкка килүе һәм хезмәт тәртибе таләпләрен һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәү мөмкин булмавы арасында сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше булуын танырга;

б) дәүләт хезмәткәренә бәйле булмаган шартларның барлыкка килүе һәм хезмәт тәртибе таләпләрен һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәү мөмкин булмавы арасында сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше булмавын танырга.»;

3.19 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.19. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «а», «б», «г», «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән мәсьәләләрне карау нәтиҗәләре буенча, аңа нигезләр булганда Комиссия әлеге Нигезләмәнең 3.11 - 3.15.1, 3.17 - 3.18.1 пунктларында каралганнан башка карар кабул итәргә мөмкин. Мондый карар кабул итүнең нигезләре һәм мотивлары Комиссия утырышы беркетмәсендә чагылдырылырга тиеш.».

Министр Р.И. Заһидуллин